**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КҮРСӘТМӘ

«05» 11 2020 ел Яр Чаллы № 190

«Тукай муниципаль районының акчалата бүләген алуга иң яхшы яшьләр проекты» конкурсын үткәрү турында

Яшьләр потенциалын тормышка ашыруга ярдәм итү, яшьләрнең иҗади эшчәнлеген активлаштыру өчен һәм Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты органнарының һәм яшьләрнең актив хезмәттәшлеге өчен шартлар тудыру максатында

**КҮРСӘТМӘ БИРӘМ:**

1. «Тукай муниципаль районының акчалата бүләген алуга иң яхшы яшьләр проекты» конкурсы турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. «Тукай муниципаль районының акчалата бүләген алуга иң яхшы яшьләр проекты» конкурсын үткәрү сметасын расларга (2 нче кушымта).
3. Тукай муниципаль районының акчалата бүләген алуга җиңүчеләрне билгеләү буенча комиссия составын кушымта нигезендә расларга (3 нче кушымта).
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Ш. Бариевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 05.11.20 190 номерлы карарына 1 нче кушымта

**«Тукай муниципаль районының акчалата бүләген алуга иң яхшы яшьләр проекты» конкурсын үткәрү турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Тукай муниципаль районының акчалата бүләген алуга иң яхшы яшьләр проекты» конкурсын үткәрү турында әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Тукай муниципаль районының акчалата бүләген алуга иң яхшы яшьләр проекты» конкурсын үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр:

1.2.1. Конкурста катнашучы – Тукай муниципаль районында теркәлгә яки Тукай районы предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшләүче 16 яшьтән 35 яшькә кадәрге Россия Федерациясе гражданы.

1.2.2. Проект – тасвирлау, исәп-хисапларны нигезләү формасына китерелгән, ниятнең асылын ачучы һәм Тукай муниципаль районы территориясендә гамәли тормышка ашыру мөмкинлеге булган фикер, идея.

## 2. Конкурсны үткәрү тәртибе

2.1. Конкурс ачык булып тора.

2.2. Конкурсның төп максатлары:

- яшьләрдә актив тормыш позициясе, районның иҗтимагый-сәяси тормышында катнашырга әзерлек формалаштыру;
- яшьләр белән эшләүнең инновацион формаларын һәм ысулларын ачыклау.

2.3. «Тукай муниципаль районының акчалата бүләк алуга иң яхшы яшьләр проекты» конкурсын (алга таба – Конкурс) Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге (алга таба – бүлек) оештыра.

Проектларны эшләү буенча тәкъдим ителгән юнәлешләр.

1. Яшьләрнең сәламәт яшәү рәвеше буенча инициативалары;
2. Яшьләрнең иҗади инициативалары;
3. Патриотик тәрбия;
4. Яшьләр медиасы;
5. Туризм һәм туган якны өйрәнү;
6. Яшьләрнең иреклелек (волонтерлык) инициативалары;
7. Милләтара һәм төбәкара татулыкны ныгыту;

8. Авыл хуҗалыгын үстерү.
9. Яшьләр эшмәкәрлеге.

2.4. Конкурс үткәрү турында мәгълүмат Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (https://tukay.tatarstan.ru/) һәм ВКонтакте социаль челтәрендә (http://vk.com/otdel_molodezhy_tuk) гаризалар кабул итү вакыты башланганчыга кадәр 2 календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштырыла һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- Конкурсны оештыручы турында мәгълүмат,
- гаризалар кабул итү вакыты, урыны һәм тәртибе,
- Конкурс үткәрелә торган юнәлешләр,
- акчалата бүләк күләме,
- конкурсны оештыручыларның элемтә телефоннары.

2.5. Конкурста катнашу өчен, Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә түбәндәге ысулларның берсе белән гариза бирелә:

- турыдан-туры Яр Чаллы шәһәре, М.Җәлил пр., 46 йорт адресы буенча яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә;
- почта элемтәсе оешмасы аша түбәндәге адрес буенча: 423800, Яр Чаллы шәһәре, М. Җәлил пр., 46 й.;
- электрон почта буенча: ilnur.G@tatar.ru.

2.6. Әлеге Нигезләмәнең 2.6 пунктында күрсәтелгән электрон почта адресына электрон документ формасында гариза җибәргәндә, конкурста катнашучы гариза электрон рәвештә җибәрелгән көннән алып өч эш көне эчендә, ләкин 2020 елның 10 декабреннән дә соңга калмыйча (10 декабрьне дә кертеп), гаризаның төп нөсхәсен кәгазьдә бүлеккә тапшырырга тиеш.

2.7. Конкурста катнашу өчен «Россия яшьләре» автоматлаштырылган мәгълүмат системасында (myrosmol.ru) теркәлергә һәм Конкурска гариза бирергә кирәк. Теркәлү һәм гариза бирү өчен инструкция бирелә (3 нче кушымта).

2.8. Конкурста катнашу өчен гариза 2020 елның 10 декабренә кадәр кабул ителә һәм кергән көнне яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегендә теркәлә.

2.9. Гаризага кәгазьдә 1 нөсхәдә һәм электрон вариантта (USB-флеш-туплагычта яки ilnur.G@tatar.ru электрон почтасы аша "Иң яхшы яшьләр проекты" тамгасы белән) проект теркәлә.

2.10. Конкурста катнашучы өстәмә материаллар (схемалар, рәсемнәр, таблицалар, макетлар, фото һәм видеоматериаллар һ.б.) тәкъдим итәргә хокуклы.

2.11. Гариза һәм проектны рәсмиләштерүгә таләпләр:

- А4 форматындагы ак кәгазьдә кара төстәге текст белән эшләү;
- текстны формалаштыру: сулдан – 3 см, уңнан – 1 см, өстән һәм астан 2 см чик калдырып;

- гариза һәм проектны рәсмиләштергәндә шрифт – Times New Roman, кегль – 12-14, юл арасындагы интервал – 1-1,5;

- проектны рәсмиләштергәндә барлык битләргә (титул биттән тыш ) уң яктан аскы почмакта номер куелган булырга тиеш;

- проектның график өлеше pdf форматында; текст өлеше xlsx, word форматында тәкъдим ителә.

2.12. Проект структурасына таләпләр:

a) титул бите (проектның исеме, проектны башкаручының исеме, конкурста катнашучы турында белешмәләр күрсәтелгән);

b) проект структурасы (А4 форматындагы 10 биттән дә артык түгел):

- проектның максаты;
- проектның бурычлары;
- социаль әһәмиятне нигезләү;
- проектны тормышка ашыру срогы;
- проектны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре;
- проектны гамәлгә ашыру чыгымнарына якынча калькуляция (2 нче кушымта).

2.13. Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә бирелгән гаризаларның әлеге Нигезләмәнең 2.6 - 2.12 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килүен гаризаны теркәгәннән соң 1 эш көне эчендә тикшерергә.

2. 14. Тикшерү нәтиҗәләре буенча яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

- гаризаны конкурста катнашу өчен кабул итү турында;
- гаризаны кабул итүдән баш тарту турында.

2.15. Гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

- гариза һәм аңа кушымталарның әлеге Нигезләмәнең 2.6 - 2.10 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве шул исәптән:

- гаризаның расланган формага туры килмәве;

- гариза бирү срокларын үтәмәү;

- Конкурста катнашучының әлеге Нигезләмәнең 1.2.1 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.

2.16. Бүлек гаризаны кабул итүдән баш тарткан очракта, тикшерү тәмамланганнан соң 2 эш көне эчендә гариза бирүчегә туры килмәү турында кире кайтаруның сәбәпләрен күрсәтеп хәбәр итә.

2.17. Мөрәҗәгать итүче әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булган сәбәпләрне бетергәннән соң, кабат гариза бирергә хокуклы.

2.18. Конкурста катнашучы гаризада һәм аңа кушымталарда бирелгән мәгълүматның дөреслеге өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка ия.

2.19. Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге гаризалар кабул итү тәмамланганнан соң ике көн эчендә Конкурста катнашу өчен кабул ителгән барлык гаризаларны «Тукай муниципаль районының акчалата бүләген алуга иң яхшы яшьләр проекты» конкурсын үткәрү комиссиясе каравына тапшыра.

2.20. «Тукай муниципаль районының акчалата бүләген алуга иң яхшы яшьләр проекты» конкурсын үткәрү буенча комиссия составы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәсе белән расланa.

2.21. Конкурска тәкъдим ителгән гаризалар һәм проектлар катнашучыларга кире кайтарылмый һәм бер ел дәвамында яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегендә саклана.

2.22. Конкурста катнашу өчен кабул ителгән барлык гаризалар Комиссия тарафыннан проектның әлеге Нигезләмәнең 2.23 пунктында билгеләнгән критерийларга туры килүне бәяләү предметына тикшерелергә тиеш, аның нәтиҗәләре буенча яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегеннән гаризалар алынган көннән 5 эш көненнән дә артмаган срокта Конкурс җиңүчесе билгеләнә.

2.23. Конкурска тәкъдим ителгән проектларны бәяләү түбәндәге критерийлар һәм баллар буенча гамәлгә ашырыла:

| Тәр-тип № | Критерий исеме | Әйе | Юк |
|---|---|---|---|
| 1 | Проектның актуальлеге һәм социаль әһәмияте (проект Тукай районында актуаль һәм социаль әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән) | 20 | 0 |
| 2 | Проект үзенчәлекле, иҗади һәм инновацион характерда | 5 | 0 |
| 3 | Автор тарафыннан проектны тормышка ашыруның мөстәкыйльлелек дәрәҗәсе | 5 | 0 |
| 4 | Проект буенча гамәлләр планы чынбарлыкка туры килә, башкарырга мөмкин һәм ресурслар белән тәэмин ителгән | 10 | 0 |
| 5 | Проектта игълан ителгән финанс таләпләре (чыгымнары) икътисадый яктан нигезләнгән һәм максатчан <1> | 20 | 0 |
| БАРЛЫГЫ | | | |

2.24. Комиссия әгъзасы әлеге Нигезләмәнең 2.23 пунктында күрсәтелгән һәр критерий буенча билгеләнгән минималь яки максималь күрсәткечләр чикләрендә гаризага баллар бирә.

2.25. Гаризаларны бәяләү нәтиҗәләре буенча Комиссия әлеге Нигезләмәнең 2.21 пунктында күрсәтелгән һәр критерий буенча комиссия әгъзалары тарафыннан гаризаны бәяләгән уртача балл суммасы нигезендә формалаштырыла торган һәр гаризаның рейтингын билгели.

2.26. Комиссия бәяләве нәтиҗәләре буенча проекты 35 тән артык балл алган Конкурста катнашучы акчалата премия алырга хокуклы.

2.27. Конкурс җиңүчесен билгеләү турында комиссия карары Комиссия тарафыннан утырышта ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш белән кабул ителә, беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм комиссия рәисе, секретаре һәм әгъзалары тарафыннан имзалана (алга таба – Комиссия карары)

2.28. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре турында, сайлап алынган катнашучылар турында, сайлап алу критерийлары буенча бәяләү, акчалата формада премия күләме турында, конкурс нәтиҗәләре буенча билгеләнгән акчалата премия алучылар турында мәгълүмат Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, ВКонтакте социаль челтәрендә яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге битендә комиссия карары кабул ителгәннән соң 3 эш көне эчендә мәҗбүри урнаштырылырга тиеш.

## 3. «Тукай муниципаль районының акчалата бүләген алуга иң яхшы яшьләр проекты» конкурсын финанслау һәм җиңүчеләргә акчалата бүләк бирү шартлары һәм тәртибе

3.1. Комиссия карары нигезендә яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге комиссия карары кабул ителгәннән соң 10 эш көне эчендә «Тукай муниципаль районының акчалата бүләген алуга иң яхшы яшьләр проекты» конкурсында җиңүчеләргә акчалата бүләк бирү турында смета әзерли.

3.2. Җиңүчеләр әлеге нигезләмә нигезендә юнәлешләр буенча билгеләнәләр һәм 22988 сум күләмендә Тукай муниципаль районының акчалата бүләге тапшырыла, шул исәптән НДФЛ – 2988 сум.

3.3. Финанслау ТР Тукай муниципаль районы бюджеты средстволары хисабына башкарыла. Конкурста җиңүчеләргә премия бирү өчен средстволар күләме 229880 сум тәшкил итә, шул исәптән НДФЛ - 29880 сум. Бүләкләнүчеләрнең максималь саны 10 кеше.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның ___ 05.11.20 ___ 190 ___ номерлы карарына 2 нче кушымта

«Тукай муниципаль районының акчалата бүләген алуга иң яхшы яшьләр проекты» конкурсын үткәрү сметасы

Иң яхшы яшьләр проекты өчен акчалата бүләк

10 кеше х 22988 сум = 229880 сум.

Барлыгы: 229880 (ике йөз егерме тугыз мең сигез йөз сиксән) сум 00 тиен.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның ___ 05.11.20 190 номерлы карарына 3 нче кушымта

«Тукай муниципаль районының акчалата бүләген алуга иң яхшы яшьләр проекты» конкурсында җиңүчеләрне билгеләү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| И.Ш. Бариев | - Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе; |
| И.Р. Гәрәев | - Башкарма комитетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы, комиссия рәисе урынбасары; |
| Н.С. Габдуллин | - «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы, комиссия әгъзасы; |
| И.И. Сәхбетдинов | - «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ директоры, комиссия әгъзасы; |
| Е.А. Дудникова | - Башкарма комитетның икътисад бүлеге җитәкчесе; |
| Р.М. Юсупова | - «Якты юл» («Светлый путь») газетасының баш мөхәррире (килешү буенча), комиссия әгъзасы; |
| Р.В. Хәбетдинов | - Тукай муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы( килешү буенча), комиссия әгъзасы; |
| Г.Н. Гаффарова | - «Тукай муниципаль районының яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» МБУнең яшьләр белән эшләү буенча белгече, секретарь. |